КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 22 октябрь г.Казань № 943

Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга социаль түләүләрне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенция рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнарына билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга социаль түләүләрне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан һәм Байконур шәһәре бюджетына бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен билгеләү методикасын раслау турында, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга социаль түләүләрне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтен гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына һәм Байконур шәһәре бюджетына федераль бюджеттан субвенцияләр бирү кагыйдәләренең 2 пунктына үзгәреш кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2019 елның 16 мартындагы 277 номерлы карарын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга социаль түләүләрне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләр рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына үз норматив актларын әлеге карарга туры китерергә.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2019 елның 27 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин